**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**07 июнь 2022 ел** **№ 14**

**Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Иске-Юмья торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Иске-Юмья авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Уставы нигезендә Ошторма-Юмья авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 18 июнена 18 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Иске Юмья авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзацларны өстәргә:

«- Иске Юмья авылында янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, янгын рукавлары, стволлар, переходниклар һәм колонкалар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- видеокамера сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Ошторма-Юмья авыл җирлеге башлыгы: С.В. Тимофеев